СОВЕТ НУРИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НӨНӘГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
25 март 2026 ел

КАРАР
№ 21

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советының 17.07.2024 № 107 карары белән расланган Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 29.12.2025 №567-ФЗ Федераль закон, Балтач районы прокуратурасының 12.03.2026 №02-08-01-2026 /Прдп90-26-20920011 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районыныц Нөнәгәр авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советының «Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында» 17.07.2024 ел, № 107 карары белән расланган Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә (29.11.2024 ел, № 118, 24.06.2025 № 137) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3.6.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

"5) тикшереп торылучы зат әлеге статьяның 1 өлешендә каралган критерийларга туры килми.»;

1.2. 3.5.6 пунктта " контроль (күзәтчелек) чаралары", сүзләрен " мәҗбүри профилактик визитлар,"сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контрольдә тотылучы затка ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча»Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында " 31.07.2020 № 248-ФЗ Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.

1.4. 3.5.1 пунктының " в " подпункты. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"в) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (әлеге Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган региональ дәүләт контроле

“в) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (әлеге Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә, федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә һәм муниципаль контроль төрләренә карата).»;

1.5. 3.5.1 пунктының 2 подпунктында. “муниципаль контроль”. “Исемлеге” сүзләрен “ муниципаль контроль” сүзләренә яисә белешмәләре классификацияләнгән урнаштыру чаралары реестрына кертелгән контрольдә тотылучы затларга алмаштырырга. Исемлек”.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән эш итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы И.Н.Закиров